ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.08.2023 г.Лениногорск № 2321

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль хезмәт белән идарә итү системасын (алга таба - муниципаль хезмәт) камилләштерү, жирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы «Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында Кодексы», «2014-2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 910 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Уставы нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Кушымта итеп бирелә торганны расларга.

2.Районның башкарма комитетына жирле һәм республика бюджетлары хисабына үткәрелә торган «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) чараларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда Лениногорск муниципаль районы бюджетында шушы максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре нигезендә Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен акча бүлеп бирүне күздә тотга.

4.Лениногорск муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Программада каралган чараларны гамәлгә ашыру чараларын күрүне, Программаны үтәүне тәэмин итү максатларында законнарда билгеләнгән тәртиптә локаль хокукый актлар эшләүне һәм кабул итүне тәкъдим итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары итеп йокләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023елның 18 августындагы 2321 номерлы карары белән расланды

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советы |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Башкарма комитеты |
| Программаның максатлары | 1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының жирле үзидарә органнары ( алга таба - жирле үзидарә органнары) тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне башкаруның нәтиҗәлелеген арттыру.<br>2. Татарстан Республикасының Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәттә кадрлар хезмәтенә заманча технологияләр кертү (алга таба муниципаль хезмәт) |
| Программаны ң бурычлары | 1. Җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша.<br>2. Лениногорск районының муниципаль хезмәткәрләре (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) муниципаль хезмәткәрләрен сайлап алу, комплекслы бәяләү механизмнарын гамәлгә кертү.<br>3. Муниципаль хезмәткәрләрнең, жирле үзидарә органнарында вазыйфа биләүче хезмәткәрләрнең, тиешенчә муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең, шулай ук кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри осталыгын һәм идарә компетентлыгын үстерү. |